Министерство образования и науки РТ
Государственное автономное образовательное учреждение
“Сабинский аграрный колледж”

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ

## ОГСЭ 06 Татарский язык в профессиональной деятельности

## По Специальности 35.02.07. Эксплуатация и ремонт с/х техники и оборудования

2019

Рабочая программа учебной дисциплины разработана на основе Федерального государственного образовательного стандарта (далее – ФГОС) по специальности СПО 35.02.16 Эксплуатация и ремонт с/х техники и оборудования.

**Согласована**

Заместитель директора ТО

___________ Р.М. Ибрагимов

31 августа 2019 года

Рассмотрена на заседании ПЦК
протокол№1 от 25.08.2019 г

**Утверждаю**

Директор ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж»

___________ **З.М.Бикмухаметов**

31 августа 2019 года

**Составитель :** преподаватель ГАПОУ «Сабинский аграрный колледж Кадырова Ч.А

## "ҺӨНӘРИ ЭШЧӘНЛЕКЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ" ФӘНЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ПАСПОРТЫ

**Программаның кулланылу өлкәсе**

"Һөнәри эшчәнлекле татар теле" уку дисциплинасыннан программа Федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә урта һәнәри белем бирүче төп программаның вариатив өлеше булып тора һәм түбәндәге белгечлек өчен кулланылырга мөмкин: 35.02.16. Эксплуатация и ремонт с/х техники и оборудования.

**1.2. Укыту фәненең төп һәнәри белем бирү программасында торган урыны:** дисциплина гомум гуманитар, социаль-экономик циклга карый.

**1.3. Укыту фәненең максат һәм бурычлары – укыту фәненең ирешеләчәк нәтиҗәләренә куелган таләпләр:**

"Һөнәри эшчәнлекле татар теле" предметын үзләштерүнең **максатлары**:

- һөнәри белем бирү кысаларында язма һәм әйтмә сөйләм культурасына ия булган белгеч әзерләү;
- студентларны татар теленең төп берәмлекләре, нормалары белән таныштыруны дәвам итү, аларны гамәлдә дөрес һәм максатчан куллану күнекмәсен камилләштерү;
- татар сөйләменең коммуникатив һәм этик үзенчәлекләрен ачу һәм, әлеге үзенчәлекләрне истә тотып, татарча нәтиҗәле сөйләм төзү күнекмәсен камилләштерү.

Предметның **бурычлары**:

- белгечләргә татар теле һәм сөйләм культурасы турында системалы белем һәм туган телнең аваз төзелеше, сүзлек хәзинәсе, грамматикасы, стилистикасы, сөйләмнең тел-сурәтләү чаралары турында белемнәрне тирәнәйтү;
- әдәби тел нормаларын тулысынча үзләштерү һәм аларны таный белү сәләтен камилләштерү;
- төрле ситуацияләрдә аралашу-сөйләшү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү;
- тел байлыгыннан ситуацияләргә һәм стильләргә мөнәсәбәтле файдалана белү;
- үзләштерелгән материалны логик эзлеклелектә аңлата белү;
- аралашуның сөйләмнән башка чараларын файдалану, аларның психологик, милли үзенчәлекләрен таный белү;
- сәнгатьле сөйләм осталыгын камилләштерү;
- лингвистик текст җирлегенә үтеп кереп, сөйләм хаталарын барлау, аларның барлыкка килү сәбәпләрен аңлату һәм хаталарны төзәтү күнекмәләрен булдырырга ирешү;
- уку йортында формалаштырылган белем һәм күнекмәләрне һөнәри эшчәнлектә кулланырга әзерләү;
- логик фикерләү, иҗат итү сәләтләрен үстерү, камилләштерү;
- мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен камилләштерү.

Программаның тел берәмлекләрен өйрәнүне һәм аларны шул ук вакытта турыдан-туры сөйләмнең эчтәлеген, идеясен ачу юнәлешендә, сөйләмнең стиленә, жанрына туры китереп дөрес куллануны күздә тотып төзелүе студентларның коммуникатив, лингвистик (тел), этномәдәни компетенцияләрен формалаштыруга юнәлтелгәнен билгели.

Һөнәри белем бирү учрежденияләрендә "Һөнәри эшчәнлекле татар теле" фәне белем бирү системасының төп үсеш юнәлешенә – системалы-эшчәнлекле юнәлешнә нигезләнгән. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән, татар теле һәм сөйләм әдәбенә дә карый. Ул, үз чиратында, коммуникатив, тел һәм лингвистик һәм этномәдәни компетенцияләрне формалаштыруны һәм үстерүне тормышка ашыра.

*Коммуникатив компетенцияләр:*

- сөйләм эшчәнлегенең бөтен төрләренә (тыңлау, уку, сөйләшү, язу) ия булу;
- телдән һәм язма сөйләм әдәбе нигезләренә ия булу;

- сөйләм максатыннан чыгып, тел берәмлекләрен нәтиҗәле куллана белү;
- сөйләм ситуациясенә карап, аралашу барлыкка килсен өчен, тел чараларын махсус сайлый белү;
- телдән һәм язма сөйләмне аңлау һәм аның эчтәлеген тиешле күләмдә сөйләп бирү;
- төрле стильдә, жанрда, типта бәйләнешле сөйләм төзү.

*Тел һәм лингвистик компетенцияләр:*

- иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак тел турындагы белемнәрне системалаштыру;
- язма һәм әйтмә сөйләмдә әдәби тел нормаларын (орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, стилистик, пунктуацион) белү, кисәтү;
- төрле сүзлекләр белән эшли белү күнекмәләрен үстерү;
- студентларның сүз хәзинәсен баету һәм сөйләмнәренең грамматик төзелешен камилләштерү.

*Этномәдәни компетенцияләр:*

- телне милләтнең мәдәни чагылышының бер формасы буларак тану;
- татар халкының тарихы һәм тел үсеше арасында бәйләнешләрне аңлау;
- татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен белү;
- милли сөйләм әдәбе нормаларын белү;
- милләтара аралашу әдәбенә ия булу.

Беренче чиратта, һөнәри эшчәнлекле татар теле дәресләре тел системасын, аның үзенчәлекләрен үзләштергән, милли үзаңга ия, милли менталитетны һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Татар теле һәм сөйләм культурасын өйрәнү укучыларның предметны югарырак дәрәҗәдә өйрәнүләрен күздә тота. Бигрәк тә, сөйләмнең функциональ стильләрен һәм сөйләм ситуациясенә мөнәсәбәтле тел берәмлекләрен, чараларын өйрәнү һәм аралашуда нәтиҗәле куллануга игътибар ителә. Программаның үрнәк эчтәлегендә сөйләм юнәлешендәге темаларга (“Сөйләм һәм тел”, “Функциональ стильләр” һ.б.) сәгатьләр саны күбрәк каралган. Мөстәкыйль эш, төрле формадагы иҗади эшләргә, рефератлар, шәхси проектлар башкаруга игътибар ителгән.

Предметны үзләштерү барышында студентларда сөйләмнең коммуникатив сыйфатын анализлый белү күнекмәләре формалаша, сөйләм әдәбеннән белемнәре тирәнәя. Шуңа күрә, тел берәмлекләрен сөйләм яссылыгында анализлау, сөйләм ситуациясенә мөнәсәбәттә һәм нәтиҗәле аралашу максатыннан аларны куллануга игътибар итү бик мөһим. Мәсәлән, лексик һәм грамматик синонимия, татар телендә сүзнең җөмләдәге урыны, аның стилитик бизәге, телнең сәнгати сурәт чаралары, сөйләм техникасы һәм башкалар киңрәк өйрәнелә.

Студент түбәндәге **гомуми компетенцияләрнең элементларын үзләштерергә** тиеш:

ОК 01. Выбирать способы решения задач профессиональной деятельности применительно к различным контекстам;
ОК 02. Осуществлять поиск, анализ и интерпретацию информации, необходимой для выполнения задач профессиональной деятельности;
ОК 03. Планировать и реализовывать собственное профессиональное и личностное развитие;
ОК 04. Работать в коллективе и команде, эффективно взаимодействовать с коллегами, руководством, клиентами;
ОК 05. Осуществлять устную и письменную коммуникацию на государственном языке Российской Федерации с учетом особенностей социального и культурного контекста;
ОК 06. Проявлять гражданско-патриотическую позицию, демонстрировать осознанное поведение на основе традиционных общечеловеческих ценностей;
ОК 09. Использовать информационные технологии в профессиональной деятельности;
ОК 10. Пользоваться профессиональной документацией на государственном и иностранном языках;

**1.4 Количество часов на освоение прграммы дисциплины**

Уку сәгатьләренең максималь саны 78 сэг. Мәҗбүри аудитор сәгатьләр 78 сэг.

## СТРУКТУРА И СОДЕРЖАНИЕ УЧЕБНО ДИСЦИПЛИНЫ

### 2.1. Объем учебной дисциплины и виды учебной работы

| **Вид учебной работы** | **Количество часов** |
|---|---|
| **Объем образовательной учебной нагрузки** | **72** |
| **Обязательная аудиторная учебная нагрузка** | **72** |
| в том числе: | |
| самостоятельные занятия | **-** |
| Теоретические часы | |
| Лаборат.практич.часы | **72** |
| Консульт.часы | **-** |
| **Промежуточная аттестация – диф.зачет** | |

## 2.2 "Һөнәри эшчәнлекле татар теле" уку дисциплинасының тематик планы һәм эчтәлеге

| Бүлек һәм теманың исеме | Уку материалының эчтәлеге, практик дәресләр, студентларның мөстәкыйль эше | Сәгать саны | Үзләш терелү дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| Кереш дәрес. Гомумкультураның бер өлеш буларак, тел һәм сөйләм культурасы. | Татар теле һәм сөйләм культурасы дисциплинасы. Гомумкультураның бер өлеш буларак, тел һәм сөйләм культурасы. Гомумтел белеменең бер тармагы буларак, сөйләм культурасы. Татар теле һәм сөйләм культурасы дисциплинасының өйрәнү объекты, максаты, бурычлары. Гомумтел белемендә сөйләм культурасы өлкәсенең өйрәнелү дәрәҗәсе. | **2** | 1 |
| **Бүлек I. Тел һәм сөйләм** | | | |
| Тема 1.1 Тел һәм сөйләм. Тел һәм сөйләмнең төп берәмлекләре, функцияләре. | Тел һәм сөйләм. Тел һәм сөйләмнең төп берәмлекләре, функцияләре. Тел һәм сөйләм арасында аерма. | **2** | 1 |
| Тема 1.2 Сөйләмгә мөнәсәбәтле ситуацияләр | Сөйләмгә мөнәсәбәтле ситуацияләр (яссылыклар) һәм аларның төрләре. Ситуацияләргә күзәтү. Сөйләм ситуациясендә сөйләм элементлары: сөйләүче, тыңлаучы, сөйләмнең темасы, вакыты, урыны, максаты, сәбәбе. Аларга күзәтү. | **2** | 1 |
| Тема 1.3 Сөйләм төрләре. Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре. | Сөйләм төрләре. Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре. Телдән һәм язма сөйләм төзү күнегүләре. | **2** | 2 |
| Тема 1.4 Сөйләм компетентлыгы | Сөйләм компетентлыгы турында төшенчә. Һөнәри сөйләм культурасы. Сөйләмнең иҗтимагый аспектлары. Сөйләм дөреслеге. Сөйләмнең эчтәлекле булуы. Сөйләм төгәллеге. Сөйләм аныклыгы. Сөйләм чисталыгы. Сөйләмнең сәнгатьлелеге, сыгылмалыгы Сөйләмнең байлыгы, матурлыгы һәм анда тел чараларын куллану. Сөйләмнең урынлы булуы. | **2** | 1 |
| Тема 1.5 Сөйләм техникасы | Сөйләм техникасы. Сулыш алу, тавыш, дикция, интонация. Сөйләмдә басым. Сәнгатьле сөйләм өчен партитура төзү. Сәнгатьле уку. | **2** | 2 |
| **Бүлек II. Сөйләмгә мөнәсәбәтле стиль ситуациясе** | | | |
| Тема 2.1 Стилистика. Стиль. Стилистиканың роле. | Стилистика. Стиль. Стилистика фәне турында төшенчә. Стилистиканың әһәмияте. Әдәби тел нормалары. "Вертикаль" яктан стильләр. Сөйләм үзенчәлекләре. Сөйләмнең функциональ стильләре. Матур сөйләм сәнгатенә хас билгеләр,хәзер-ге сөйләм теле этикасы нормалары. Сүзнең асылы, сөйләмдә аның төп роле. Логик эзлекле, эмоциональ, ышандырырлык бербөтен мәгънәгә ия булган сөйләм телен үстерү. | **2** | 2 |
| Тема 2.2 Әдәби сөйләм һәм язма стильләр. Фәнни стиль. | Әдәби сөйләм һәм язма стильләр, аларның төрләре. Фәнни, рәсми-канцелярия, иҗтимагый-публицистик, хатлар һәм матур әдәбият стиле. Стильләрнең кулланылыш сферасы. Фәнни стиль. Фәнни стильгә хас үзенчәлекләр. Фәнни стиль жанрлары. Публицистик стиль. Доклад, реферат, шәхси проект, чыгарылыш квалификацион эш, автореферат язуга таләпләр. Фәнни – проект эшчәнлеге. | **2** | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 2.3 Публицистик стиль. Татар матбугаты тарихы һәм бүгенге торышы. | Татар халкында матбугатның формалашуы. Татар матбугатының барлыкка килүе, үсеше өчен алшартлар. Аның халыкка, аң үсешенә йогынтысы. Җәмгыятьтә тоткан урыны. Матбугатны формалаштыручы, үстерүгә өлеш керткән шәхесләр. | 2 | 2 |
| Тема 2.4 Фәнни стиль жанры: **рецензия.** | Рецензия. Рецензия язуга төп таләпләр. Газета һәм журналларны рецензияләү. | 2 | 2 |
| Тема 2.5 Фәнни стиль жанры: **аннотация.** | **Аннотация** Аннотация – текстның, китапның кыскача эчтәлеген бирү, күзәтү ясау, анализлау, китапка үз фикереңне белдерү. Аннотация язарга өйрәнү, сакланырга тиеш төп шартлар. Әдәби әсәрләргә аннотация язу. | 2 | 2 |
| Тема 2.6 Рәсми-канцелярия стиле. Гариза, боерыклар. | Рәсми-канцелярия стиле. Рәсми-канцелярия стиленә хас үзенчәлекләр. Рәсми-канцелярия стиле жанрлары. Боерыклар. Аларның төрләре: эшкә алу, эштән азат итү турында боерыклар.<br>Боерык тутыруга төп таләпләр. Гариза – язма рәвештә рәсми формада язылган шәхси үтенеч. Гаризаның төрләре. Гаризаны дөрес, грамоталы итеп язарга өйрәнү. | 2 | 2 |
| Тема 2.7 Резюме, сыйфатнамә язу. | Сыйфатнамә. Төркемдәшеңә сыйфатнамә язу. Резюме. Үз резюмеңны тутыру принципларын үзләштерү. | 2 | 2 |
| Тема 2.8 Мәгълүматнамә, расписка, беркетмә. | **Мәгълүматнамә, расписка язуга таләпләр.** Шартнамәләр. Төрләре. Төзү тәртибе. Мәгълүматнамә – җитәкчегә эш турында язма рәвештә бирелә торган рәсми мәгүлүмат. Мәгълүматнамә язарга өйрәнү.<br>Беркетмә – җыелыш, киңәшмә, утырышларның барышын төгәл язып баручы документ. Беркетмә язарга өйрәнү. | 2 | 2 |
| Тема 2.9 Акт, ышанычнамә язуга таләпләр. | **Акт, ышанычнамә язуга таләпләр.** Ышанычнамә. Билгеләмә. РФ ГК ның 185- 189 статьялары. Төрләре. Ышанычнамә тутыруга төп таләпләр. Акт – нинди дә булса юридик факт турында документ. Актны грамоталы төзергә өйрәнү. | 2 | 2 |
| Тема 2.10 Иҗтимагый-публицистик стиль. | Иҗтимагый-публицистик стиль. Иҗтимагый-публицистик стиль үзенчәлекләре. Төп жанрлары. Мәкалә язу. | 2 | 2 |
| Тема 2.11 Хатлар стиле. Рәсми һәм шәхси хатлар. | Хатлар стиле. Хатларның төрләре. Хатларның төрләренә карап, аларны язу стиле. Хатлар. Төрләре. Рәсми һәм шәхси хатлар. Күмәк, матбугат, ачык хатлар. Җавап таләп итүче һәм җавап таләп итмәүче хатлар. | 2 | 2 |
| Тема 2.12 Матур әдәбият стиле. | Матур әдәбият стиле. Матур әдәбият стилендәге текстларның төрләре, жанрлары. Әдәби әсәрләрнең композициясе. Әдәби әсәрләрнең теле. Матур әдәбият стиле, стилистик бизәкләр. Төшенчәләрне белдерүдә синонимнарның роле. Образлы сөйләмдә капма – каршылыклы белдерүнең махсус чарасы буларак – антоним. Төшенчә һәм образ. Сүзнең эчке формасы | 2 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | һәм образлылык.<br>Бүлек буенча белемнәрне системалаштыру, тикшерү. | | |
| **Бүлек III. Текст. Текст төзелеше** | | | |
| Тема 3.1 Сөйләмнең төп өйрәнү объекты буларак текст. | Сөйләмнең төп өйрәнү объекты буларак текст. Текст һәм аның микро һәм макротекстка бүленүе. Текст һәм абзац. Текстның мәгънәви, коммуникатив, структур, грамматик бөтенлеге. Текст композициясе. | **2** | 1 |
| Тема 3.2 Сөйләмнең мәгънәви-функциональ типлары. | Сөйләмнең мәгънәви-функциональ типлары. Төрле типтагы (сурәтләү, фикерләү, хикәяләү) текстлар төзү. Текстта җөмләләр бәйләнешен белдерү ысуллары. Тексның синтаксисы. | **2** | 2 |
| Тема 3.3 БСҮ Бирелгән текст буенча тыгыз (сжатое) изложение. | Бирелгән текст буенча тыгыз (сжатое) изложение язу. | **2** | 3 |
| Тема 3.4 Сөйләмгә мөнәсәбәтле тел ситуациясе. Әңгәмә. | Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләр. Әңгәмә коруның төп юнәлешләре. Әзерлексез чыгыш ясауның үзенчәлекләре: үз-үзеңне тота белү (мимика), сөйләмнең төп фикерен җиткерә белү, кереш һәм йомгаклау сүзен формалаштыру. Әңгәмә - иҗтимагый тормышның иң әһәмиятле бер күренеше:<br>- Әңгәмәнең асылы һәм аның типлары: якыннарың белән әңгәмә; таныш булмаган кеше белән әңгәмә; эшлекле әңгәмә; өстәл яны әңгәмәсе.<br>- Әңгәмә коруның ике моделе: “ачык” сөйләм һәм “ябык” сөйләм.<br>Комплимент һәм тостлар әйтә белү. Әңгәмә коруның төп юнәлешләре.<br>**Практик дәрес.** | **2** | 2 |
| **Бүлек IV. Лексика һәм сөйләм культурасы** | | | |
| Тема 4.1 Татар теленең лексикасы. Лексикология. Лексикография. Сүзлекләр. Төрләре. | Лексика, лексикология төшенчәләре. Семасиология, этимология, фразеология, лексикография, ономастика. Сүзлекләр. Төрләре. Функцияләре. Сүзлекләргә күзәтү, характеристика бирү.<br>Көнкүреш сөйләм теленең кулланылыш сферасы, лексика составы. Дублет һәм күрсәткеч сүзләрнең сөйләмдә кулланылышы һәм урыны. | **2** | 2 |
| Тема 4.2 Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Сүзнең күпмәгънәлелеге Синонимнар. Синонимнарның стилистик кулланылышы. | Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Күчерелмә мәгънәле сүзләрнең стилистик кулланылышы. Сүз мәгънәләре. Сүзнең күпмәгънәлелеге. Күпмәгънәле сүзләр һәм сөйләм культурасы. Омонимнар. Омонимнарның төрләре. Омонимнарның стилистик к Синонимнар. Синонимнарның төрләре: сүзгә-сүз, грамматик, лексик-грамматик. Синонимнарның стилистик кулланылышы. Синонимнарны куллануда хаталар.улланылышы. | **4** | 2 |
| Тема 4.3 Фразеологик берәмлекләр. Аларны сөйләмдә куллану. | Фразеологик берәмлекләр. Аларны сөйләмдә куллану. Фразеология һәм сөйләм культурасы. Фразеологик берәмлекләрнең төп билгеләре һәм аларның төрләре. Фразеологизмнарның стилистикасы. | **2** | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тема 4.4 Килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы. | Татар теленең сүзлек составы һәм сөйләм культурасы. Килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы. Татар теленең нигезе буларак гомумтөрки сүзләр. Татар телендә алынмалар. Татар телендә гарәп-фарсы, рус, европа телләреннән алынган сүзләр. Аларның сөйләмдә кулланылышы. | 2 | 2 |
| Тема 4.5 Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. | Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Татар теленең сүзлек составында актив һәм пассив катламнар. Искергән сүзләр буларак тарихи сүзләр һәм архаизмнар. Яңа сүзләр (неологизмнар) һәм аларның барлыкка килү юллары. Татар теленең диалекты. | 4 | 2 |
| Тема 4.6 Сөйләмнең сәнгатьчә сурәтләү алымнары | Сөйләмнең сәнгатьчә сурәтләү алымнары: эпитет, чагыштыру, метафоралар, метонимия, сынландыру, арттыру, антитеза, оксюморон, литота һ.б. Антитеза(төшенчәләрне капма –каршы куеп, фикер,фраза тудыру) һәм градация (төшенчәләрнең мәгънәләре үсә һәм кими бару тәртибендә урнашуы) үзенчәлекләре. Оксюморон(образны капма –каршылыклы күренешләрнең бердәмлегә аша сурәтләү) – үткен мәгънәле фикерне оештыручы фигура. Сөйләмдә лексик хаталарның типлары. | 2 | 2 |
| Тема 4.7 Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. | Сөйләм этикасы нормалары. Аудиториядә чыгыш ясау үзенчәлекләре. Әзерлексез чыгыш ясауның үзенчәлекләре: үз-үзеңне тота белү(мимика), сөйләмнең төп фикерен җиткерә белү, кереш һәм йомгаклау сүзен формалаштыру. Риторик эндәш һәм сорау – сөйләмдә әһәмиятле мәгънәви позицияне билгеләү, тыңлаучының фикерен үзең теләгәнчә формалаштыру өчен кулланыла торган фигуралар. | 2 | 2 |
| Тема 4.8 Һөнәри лексика өстендә эшләү. | Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш. Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау. Сөйләм культурасы. | 2 | 2 |
| Тема 4.9 Һөнәри лексика өстендә эшләү. | Һөнәри лексика. Терминнар. Һөнәри юнәлешкә караган текстлар белән эш. Һөнәри лексика темасына сүзлек диктанты язу. Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш. Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау. | 4 | 2 |
| Тема 4.10 Һөнәри лексика өстендә эшләү. | Һөнәри лексика. Терминнар. Һөнәри юнәлешкә караган текстлар белән эш. Һөнәри лексика темасына сүзлек диктанты язу. Һөнәри лексика өстендә эшләү. Сүзлекләр белән эш. Терминологик сүзлекләр белән эш. Сайланган һөнәр буенча сүзләр туплау. Бүлекне йомгаклау. Белемнәрне ткшерү. | 2 | 2 |
| Һөнәри эшчәнлекле татар теле курсын йомгаклау. | Дифференциальләштерелгән зачет. | 2 | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дифференциальлэштерелгэн зачет. | | | |
| **Барлыгы** | | **78** | |

Для характеристики уровня освоения учебного материала используются следующие обозначения:

1. – ознакомительный (узнавание ранее изученных объектов, свойств);
2. – репродуктивный (выполнение деятельности по образцу, инструкции или под руководством)
3. – продуктивный (планирование и самостоятельное выполнение деятельности, решение проблемных задач)

## 4. Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм бәя

Укыту дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм бәя укытучы тарафыннан катнаш, гамәли дәресләр уздырганда, мөстәкыйль һәм конроль, сөйләм культурасының тикшерү эшләре уздыру барышында, тестлар үтәгәндә, төрле характердагы фәнни-иҗади эшләр башкарганда тормышка ашырыла.

| **Укытуның нәтиҗәләре (белем, күнекмәләр)** | **Компетенция элементлары** | **Контроль һәм бәяләү форма һәм методлары** |
|---|---|---|
| сөйләм эшчәнлегенең бөтен төрләренә (тыңлау, уку, сөйләшү, язу) ия булу | ОК 1. Выбирать способы решения задач профессиональной деятельности применительно к различным контекстам;<br>Элементлары: сайлаган һәнәрнең әһәмиятен, җәмгыятьтә тоткан урынын аңлауны текстлар белән эш барышында күрсәтә | практик эшләр башкпару аша;<br>группалап оештырылган эшләрне бәяләү аша; |
| телдән һәм язма сөйләм әдәбе нигезләренә ия булу | | диспутларда, фикер алышуда катнашу аша бәялзәү; |
| сөйләм максатыннан чыгып, тел берәмлекләрен нәтиҗәле куллана белү | | практик дәресләр аша бәяләү;<br>иҗади эш башкаруәйтмә һәм язма телне үстерүгә юнәлтелгән күнегүләр башкару аша. |
| сөйләм ситуациясенә карап, аралашу барлыкка килсен өчен, тел чараларын махсус сайлый белү | ОК 6. Проявлять гражданско-патриотическую позицию, демонстрировать осознанное поведение на основе традиционных общечеловеческих ценностей;<br>Элементлары:<br>группалап эшләү барышында эш темпын корректлаштыра;<br>группа эшчәнлегендә хезмәттәшлеккә омтылыш күрсәтү;<br>уку мәсьәләләрен чишү барышында башкаларга ярдәм итәргә омтылыш<br>Группалап эшләү барышында группаның эшен оештыру | практик дәресләр аша бәяләү; |
| телдән һәм язма сөйләмне аңлау һәм аның эчтәлеген тиешле күләмдә сөйләп бирү | | студентларның практик биремнәр башкару ярдәмендә;<br>дифференциальләштерелгән зачет. |
| төрле стильдә, жанрда, типта бәйләнешле сөйләм төзү | ОК 1. Выбирать способы решения задач профессиональной деятельности применительно к различным контекстам;<br>Элементлары:<br>төрле характерлы текстлар белән эш барышында сайлаган һөнәрнең асылына төшенү | Практик дәресләр аша бәяләү;<br>иҗади эш башкару; |
| иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак тел турындагы белемнәрне системалаштыру | ОК Работать в коллективе и команде, эффективно взаимодействовать с коллегами, руководством, клиентами;<br>Элементлары:<br>тиешле материалны чыганаклардан табу;<br>мәгълүматны Интернет һәм башка чаралар ярдәмендә табу;<br>мәгълүматны эшкәртү<br>басма һәм онлайн сүзлекләр белән | студентлар тарафыннан башкарылган презентацияләр аша; |
| язма һәм әйтмә сөйләмдә әдәби тел нормаларын (орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, стилистик, | | дифференциальләштерелгән зачет барышында;<br>әйтмә һәм язма телне үстерүгә юнәлтелгән күнегүләр башкару |

## 3. Уку дисциплинасын тормышка ашыру шартлары

**3.1.Минималь материаль-техник тәэмин ителешкә таләпләр**

Уку дисциплинасын тормышка ашыру өчен махсус "Туган телне өйрәнү кабинеты" каралган.

**Уку кабинетының җиһазлары:**

- укучылар санына карап, уку-утыру урыннары;
- укытучының эш урыны;
- укыту эчтәлеген билгеләүче укыту-норматив документлар:
  - Федераль дәүләт белем бирү стандарты;
  - уку программасы;
  - календарь-тематик план;
- татар теленнән дәреслекләр, күнегү җыентыклары, сүзлекләр;
- укытучы һәм укучылар өчен ярдәмлекләр;
- күрсәтмә һәм күргәзмә уку әсбаплары (таблицалар, схемалар, картиналар, рәсемнәр, портретлар һ.б.);
- таратма материаллар (карточкалар, тестлар);
- контроль – үлчәү материаллары
- тел һәм әдәбият белеменә караган фәнни чыганаклар;
- тел һәм әдәбияттан мультимедия материаллары.

Укытуның техник чара белән тәэмин ителеше:

- компьютер һәм мультимедиа проекторы.

**3.2. Укытуның мәгълүмати тәэмин ителеше**

**Төп чыганаклар**

*Төп чыганаклар:*

1. Юсупов Р.А.Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит. нәшр. 2014. – 287 б.

*Өстәмә чыганаклар:*

1. Абдуллина, Р. С. Сөйләм культурасы – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012 – 527 б.

**Интернет ресурслар:**

1. www.mon.tatar.ru
2. Татар теле һәм әдәбияты — Википедия ru.wikipedia.org›wiki / Татар теле
3. http://www.tugantelem.narod.ru

| | | |
|---|---|---|
| пунктуацион) белү, кисәтү | эшли | аша |
| төрле сүзлекләр белән эшли белү күнекмәләрен үстерү | | Сүзлекләрне анализлау. |
| Рәсми стильне (эш кәгазьләре стиле) таный белү, рәсми стильгә караган үрнәкләрне таный белү | | Практик эшләр башкару, аларны бәяләү ярдәмендә; |
| сөйләм стильләрен аера, таный белү, стиль төзүче компонентларны танып куллана белү | ОК 1. Выбирать способы решения задач профессиональной деятельности применительно к различным контекстам; Сөйләм стильләре, аларга кагылышлы күнегүләр башкару барышында сайлаган һөнәрнең асылына төшенү | Төрле стиль үрнәкләрен төзү барышында, практик күнегүләр башкару ярдәмендә; |
| рәсми стиль үрнәкләре белән эш итә белү | | практик күнегүләр башкару ярдәмендә |
| студентларның сүз хәзинәсен баету һәм сөйләмнәренең грамматик төзелешен камилләштерү | ОК5. Осуществлять устную и письменную коммуникацию на государственном языке Российской Федерации с учетом особенностей социального и культурного контекста;<br>Элементлары:<br>Фәнни – эзләнү эшләре, проект башкара белә;<br>Чыганаклардан материал туплау, эшкәртү, анализ ярдәмендә доклад, реферат, текстлар төзи белә. | монологик сөйләмне анализлау ярдәмендә дифференциальләштерелгән зачет |
| татар халкының тарихы һәм тел үсеше арасында бәйләнешләрне аңлау | | туган тел, татар әдәбиятыннан оештырылган чараларда катнашу; |
| татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен белү | ОК 6. Проявлять гражданско-патриотическую позицию, демонстрировать осознанное поведение на основе традиционных общечеловеческих ценностей;<br>Элементлары:<br>группалап эшләү барышында эш темпын корректлаштыра;<br>группа эшчәнлегендә хезмәттәшлеккә омтылыш күрсәтү;<br>уку мәсьәләләрен чишү барышында башкаларга ярдәм итәргә омтылыш<br>Группалап эшләү барышында группаның эшен оештыру | биремнәрне үтәү |
| милли сөйләм әдәбе нормаларын белү | | әйтмә һәм язма телне үстерүгә юнәлтелгән күнегүләр башкару аша;<br>дифференциальләштерелгән зачет |
| милләтара аралашу әдәбенә ия булу. | | Күпмилләтле җирлектә аралашу әдәбен күзтү аша; турле чараларда катнашу, җәлеп итү ярдәмендә |